**Республика Татарстан**
**Совет Бугульминского**
**муниципального района**
**III созыва**

**Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль**
**районы Советы**
**III чакырылыш**

423230, город Бугульма,
ул. Гафиатуллина, дом7
телефон: (85594) 4-25-00, 4-37-44

423230, Бөгелмә шәһәре,
Гафиятуллин урамы, 7нче йорт,
телефон: (85594) 4-25-00, 4-37-44

14 августа 2019 года

**ЕГЕРМЕ ТУГЫЗЫНЧЫ СЕССИЯ**

**8нче КАРАР**

**Татарстан Республикасы
Бөгелмә муниципаль районы территориясендә
җирләрне җирле әһәмияткә ия булган
аеруча саклаулы территорияләр
җирләренә кертү тәртибе турындагы
Нигезләмәне раслау турында**

Россия Федерациясенең Җир турындагы кодексына, 1995 елның 14 мартында кабул ителгән “Аеруча саклаулы табигый территорияләр турында”гы №33-ФЗ Федераль Законына һәм Татарстан Республикасы “Бөгелмә муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

**Бөгелмә муниципаль районы Советы**

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы территориясендә җирләрне җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы территорияләр җирләренә кертү тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга (1нче кушымта).
2. Әлеге карар күмәк мәгълүмат чараларында рәсми төстә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Бөгелмә муниципаль районы башлыгы урынбасары Ф.В. Мөхәммәтовка йөкләргә.

**Бөгелмә муниципаль
районы башлыгы** **Л.Р.Закиров**

Бөгелмә муниципаль районы
Советының 2019 елның
14 августында булып узган
XXIX сессиясенең
8нче карарына
1нче кушымта

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы территориясендә җирләрне җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы территорияләр җирләренә кертү тәртибе турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы территориясендә җирләрне җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы территорияләр җирләренә кертү тәртибе турындагы әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Россия Федерациясенең Җир турындагы кодексының 94нче маддәсенә, 1995 елның 14 мартында кабул ителгән "Аеруча саклаулы табигый территорияләр турында"гы №33-ФЗ Федераль Законына һәм Татарстан Республикасы "Бөгелмә муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып эшләнде һәм Бөгелмә муниципаль районы (алга таба – Район) территориясендә җирләрне җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы территорияләр җирләренә кертү тәртибен билгели.

2. Район территориясендә җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы территорияләр җирләренә түбәндәге җирләр керәләр:

1) аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге;

2) табигатьне саклау максатындагы;

3) рекреацион максаттагы;

4) тарихи-мәдәни максаттагы;

5) аеруча кыйммәткә ия булганнары.

3. Җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы территорияләр булдыру турындагы карарны Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) кабул итә.

Башкарма комитет Район милеге булган җир участокларында җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы табигый территорияләр булдыра. Җирле әһәмияткә ия булган ул аеруча саклаулы табигый территория Район карамагындагы барлык җир участогының тулаем мәйданының биш процентган артык урынын биләп тора икән, Башкарма комитет аеруча саклаулы табигый территория булдыру турындагы карарны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештерә.

4. Район территориясендә җирләрне җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы табигый территорияләр җирләренә кертү турындагы карар проектын Бөгелмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы әзерли һәм анда түбәндәнге мәгълүматлар булырга тиеш:

- һәр җир участогын җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы табигый территориягә кертү зарурлыгын нигезләү;

- җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы табигый территориянең урнашкан урыны, мәйданы, категориясе, саклану режимы һәм файдалану тәртибе;

- аеруча саклаулы территориянең чикләрен тасвирлау;

- җир участокларын җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы табигый территориягә кертүдән (кертмәүдән) киләчәк ихтимал-нәтиҗәне (зыянны) исәпләү.

Карарга, муниципаль җир участокларының чикләре, җир участокларының хуҗалары, җиргә ия кешеләр, җир участокларын арендага алган кешеләр һәм сервитут ияләре күрсәтелгән план-картография материаллары белән бергә, җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы табигый территория җирләре составына кертелә торган җир участокларының исемлеге дә кушып бирелә.

5. Җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы табигый территория җирләренең урындагы чикләре әлеге карар нигезендә билгеләнә.

6. Җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы табигый территория дип танылган территорияләр өчен оештыру-техник һәм башка чаралар эшләнә, гамәлгә ашырыла, атап әйткәндә:

- территорияләрне төзекләндерү;

- табигый ресурсларны өстәмә өйрәнү;

- чикләрне билгеләү һәм эшләү режимын ачыклау турында тәкъдимнәре булган проектлау-техник документацияне әзерләү;

- саклау формасы;

- урында санитар саклау чикләрен билгеләү һәм җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы табигый территориядә табигый мохитнең торышына даими күзәтчелек итү;

7. Җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы табигый территория составында өлешчә хуҗалыкта кулланыла торган махсус билгеләнгән җир участокларында алар өчен эшләнгән аерым хокукый режимга туры китереп, хуҗалык һәм рекреация эшчәнлеген чикләүгә юл куела ала.

8. Җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы табигый территория җирләре чикләрендә җирнең максатчан кулланылу максатын үзгәртү яки аларның максатчан кулланылуына каршы килә торган ихтыяҗларда җиргә хокукны башкача туктатуга юл куелмый.

9. Җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы табигый территориянең урнашу һәм үсеше схемасында каралмаган җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы табигый территория гражданнар тәкъдимнәре буенча һәм шулай ук җәмәгать берләшмәләре һәм коммерцияле булмаган оешмалар тәкъдимнәре белән дә булдырыла ала.

10. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә эшчәнлек алып баручы гражданнар, шулай ук җәмәгать берләшмәләре һәм коммерцияле булмаган оешмалар аеруча саклаулы табигый территорияләр оештыру, саклау һәм файдалану чараларын гамәлгә ашыруда Башкарма комитетка теләктәшлек күрсәтергә һәм ярдәм итәргә хокуклылар.

11. Башкарма комитет әлеге тәкъдимнәрне карый, нигез булган очракта, аеруча саклаулы территория оештыру өчен материаллар әзерләү турында карар кабул итә яки мотивацияле рәвештә баш тарта.

12. Җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы табигый территория җирләренең чикләрен раслау җир участокларын җирле әһәмияткә ия булган саклаулы территорияне саклау һәм файдалану режимына туры килми торган максатларда куллануны туктатуга нигез булып тора. Эшчәнлеге әлеге территориядә башкару функцияләренә ярашмый торган затлардан җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы территория чикләрендә урнашкан җир участокларын тартып алу һәм аңа бәйле зыянны каплау гамәлдәге законда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

13. Аеруча саклаулы территория оештырылганнан соң алты ай вакыт эчендә әлеге территория җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы табигый территориянең үсеше схемасына кертелә.

14. Җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы табигый территория җирләрендә аларның категориясенә, максат һәм бурычларына, мәйданына, табигый һәм тарихи-мәдәни, шәһәр төзелеше үзенчәлекләренә һәм башкаларга бәйле рәвештә берничә төрле зонага һәм участокларга бүленә ала, шул исәптән:

- табигатьне саклау һәм фәнни максатларда файдалану өчен билгеләнгән һәм табигатьтә аеруча кыйммәтле саналган бергәлекләрне, сирәк очрый торган яки бетеп бара торган үсемлекләрне яки җәнлекләрне, тере һәм тере булмаган башка табигый объектларны саклап калу, торгызу максаты белән булдырылган тыюлыклар;

- тарихи-мәдәни мирас объектларын саклау һәм торгызу өчен булдырылган, фәнни һәм мәгърифәт-агарту максатларында кулланыла ала торган тарихи-мәдәни мирас объектларын саклау зоналары;

- халыкка экологик аң-белем бирү һәм тәрбияләү өчен билгеләнгән укыту-экскурсия зоналары. Укыту-экскурсия зоналарында уку-өйрәнү һәм танып-белү маршрутлары оештырыла ала;

- халыкның күмәкләп ял итүе өчен махсус көйләнгән һәм булдырылган рекреация үзәкләре;

- аерым-аерым һәм төркемләп физкультура белән шөгыльләнү өчен булдырылган һәм шул максатларга махсус көйләнгән физкультура-сәламәтләндерү зоналары ;

- карап-күзәтеп, ял итеп йөрү зоналары.

15. Җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы табигый территориянең категориясен үзгәртү яки кыскарту Башкарма комитет тәкъдиме белән башкарыла. Җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы территориянең категориясен үзгәртү өчен нигез булып торалар:

- аеруча саклаулы территорияне саклау режимын көчәйтү зарурлыгы;

- аеруча саклаулы территориянең нигезе булып торган табигый һәм (яки) тарихи-мәдәни объектларның һәлакәтенә, юкка чыгуына китергән гадәттән тыш экологик вәзгыять.

16. Җирле әһәмияткә ия булган аеруча саклаулы табигый территориянең категориясен үзгәрткәндә, әлеге территориянең чикләре кабат каралмый.